КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
Журналистика һәм социлогогия факультеты
Татар журналистика кафедрасы

# МАСТЕР – КЛАСС:

# РЕГИОНАЛЬ МАТБУГАТТА ИНТЕРВЬЮ ЖАНРЫ

УКУ ПРОГРАММАСЫ

КАЗАН

2011

**УДК 070**

*Печатается по решению Редакционно-издателького совета*
*ФГАОУВПО «Казанский (Приволжский) федеральный университет»*
*учебно-методической комиссии факультета журналистики и социологии*
*Протокол № 5 от июня 2011г.*
*заседания кафедры татарской журналистики*
*Протокол № 9 от 18 апреля 2011г.*

**Автор – составитель**
кандидат филологических наук Л.Р. Сабирова

**Научный редактор**
доктор филологических наук, профессор КФУ В.З. Гарифуллин

**Рецензент**
кандидат филологических наук, доцент КФУ Р.Л. Зайни

**Сабирова Л.Р.**
**Мастер класс: региональ матбугатта интервью жанры:** учебная программа. Казань: Казанский университет, 2010. – 15 с.

Основная задача курса – дать студентам необходимые навыки оперативного создания новостного текста, а именно, интервью для разных типов печатных СМИ.

# Кереш

Журналист булырга җыенучы студент жанр төркемнәрен аера белергә тиеш. Жанрларны өйрәнүнең практик әһәмияте зур. Заманалар үзгәрү белән кайбер жанрлар кулланылыштан төшеп калырга, ә кайберләре исә үсеш кичерергә мөмкин. Шундый үсеш-үзгәреш кичерүче жанрлар арасында интервью аерым урын алып тора.

Интервью – шәхеснең тышкы кыяфәте, холкы, һөнәре, социаль дәрәҗәсен ачыклау һәм алынган нәтиҗәләрне сәнгати чаралар белән вакытлы матбугат, радио, телевидение, интернетта аудиториягә тәкъдим итү чарасы. Кызыклы интервью оештыру җиңел эш түгел. Бу жанр хәбәрчедән ныклы әзерлек, башкалар белән тиз аралашу, уртак тел таба алу, күңелен сизгер тою кебек мөһим сыйфатлар таләп итә. Әңгәмә алдыннан максатыңны төгәл билгеләргә, теманы конкретлаштырырга кирәк. Нәрсә хакында, ничек сөйләшәсеңне ныклап уйлап куйганда, интервьюның уңышлы чыгачагына өмет итеп була. Сораулар максатка ярашлы булсын һәм әңгәмә кызыклы үтсен өчен, сүз бара торган мәсьәлә буенча әзерлекле булырга кирәк.

Программа студентларны журналист буларак нәтиҗәлеккә ирешү алымнарына өйрәтүне, иҗади эшчәнлеген камилләштерүне, интервью жанрын һәр яклап өйрәнүне күздә тота.

Дәресләрдә теоретик белемнәрне конкрет мисалларда, гамәлдә кулланырга, басманың аудиториясен күздә тотып, интервью жанрында иҗат итәргә өйрәтү максат итеп куела. Практик дәресләрдә белемнәрне яхшырак үзләштерү өчен психологик тренинглар, уеннар, кунаклар чакырылуы каралган.

Укыту **бакалавриат** әзерләү планы буенча алып барылганда, **“Иҗади-профессиональ практикум”** модуль курсы кысаларына керә. Дисциплина түбәндәге компетенцияләрне формалаштыруга юнәлтелгән: ММЧда мәгълүматка карата куела торган таләпләрне үзләштерү, хәбәри журналистиканың үзенчәлекләренә төшенү, актуаль теманы табып, аны ачып

бирергә өйрәнү, һәр басманың нинди типтан булуына карап, оператив рәвештә материалны эшкәртергә өйрәнү, техник стандартларга нигезләнеп, матбугатка бастыру өчен материал әзерләү (дәүләт стандарты буенча ОК-19, ПК-29, ПК-40, ПК-32, ПК-33, ПК-39 пунктлар).

Курсны өйрәнү ахырында **студент:**

- хәбәри журналистиканың асылын белергә, мәгълүмат белән эш итәргә, журналист әсәренең спецификасын, структурасын һәм композиция үзенчәлекләрен үзләштерергә тиеш;
- интервью өчен актуаль теманы таба белергә, оператив рәвештә материалны әзерләп, басманың аудиториясен һәм тибын күздә тотып, тел-стиль чараларын үзенчәлекләрен белеп, лид, баш исемнәрне җиңел куя белергә тиеш;
- мәгълүмат туплау методлары, интервью технологиясен, документлар белән эш итү, анализ, селекция кебек методлар белән таныш булырга тиеш.

**“Мастер класс: региональ матбугатта интервью жанры”** дисциплинасы көндезге уку бүлегенең V курс студентлары өчен. 030601.65 (021400) – “Журналистика” белгечлеге буенча әзерләнә. План буенча **72** сәгать каралган, I семестрда укытыла. Имтихан белән төгәлләнә. **Бакалавриат** планы буенча алып барылганда, ул “Иҗади-профессиональ практикум” модуль курсы кысаларында укытыла. Аңа **I** курсның **II** семестрнда **32** сәгать каралган. Зачет белән төгәлләнә.

## ПРОГРАММА

***Кереш тема:*** «Региональ матбугатта интервью жанры» курсы, аның эчтәлеге, максаты, бурычлары, өйрәнү тәртибе. Әдәбият исемлеге белән таныштыру. Региональ матбугатка күзәтү. Анкета тутыру.

***Беренче тема:*** **Журналистикада жанрлар системасы**

Хәбәри, аналитик, әдәби-публицистик жанрлар. Интервьюның жанрлар системасындагы урыны. Интервью жанрының популярлыгын исбатлау. Хәбәри жанрның билгеләре: оперативлык, документальлек, төгәллек һ.б..

Региональ массакүләм мәгүлүмат чараларының сыйфаты, аерылып торган яклары һәм үзенчәлеге.

***Икенче тема:*** **Нәрсә ул интервью?**

Жанр буларак интервью. Интервью жанрының билгеләмәсе. Аның хәбәри төрләренә караган интервью-диалог һәм интервью–монолог төрләренең асыл сыйфатлары.

Интервью жанрның типологиясе: протокол интервью, интервью-фикер, интервью-факт, портрет-интервью, проблемалы интервью (дискуссия), интервью-анкета, интервью-түгәрәк өстәл, эсклюзив интервью, блиц-нтервью, офф-лайн интервью, чат һ.б. Аларның сыйфатлары, үзенчәлекләре (мисаллар белән дәлилләү).

***Өченче тема:*** **Алым буларак интервью**

Чынбарлыкны чагылдыру алымы буларак интервьюның төрләре: әңгәмә, сөйләшү, интервью үзе, сорау алу. Материалны күрсәтү алымы буларак, диалог, монолог, полилог төрләре. Аларның төп сыйфатлары. Теманы ачар өчен мәгълүмат туплаганда интервьюның роле.

***Дүртенче тема:*** **Интервью жанрның татар матбугатындагы тарихы**

Интервью жанрның барлыкка килүе. Аның беренче үрнәкләре (“Аң”, “Азат”, “Йолдыз”). Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Колахмәтов язмалары. Ул чордагы интервьюның сыйфаты, төрләре.

Бүгенге көндә интервью жанрының популярлыгын аңлату. Татар теленең үсешендә тоткан урынын билгеләү. Интервьюның сөйләмдә неологизм,

диалектизм, жаргон, профессионализм кебек күренешләрнең үсешендә тоткан урыны.

***Бишенче тема:*** **“Һәр журналист сорау бирә”**

Сорауларның төп функциясе, аларны әзерләү үзенчәлеге. Интервьюда сорауларның éîìøàê êœ÷åøëå Ÿ□ì êèñêåí êœ÷åøëå òšçåëåø òšðë□ðå. Соруларны мәгънәләре ягыннан тикшерү. Сорауларның төрләрен ачыклау (контактлы, адреслы, тематик һ.б.).

Алдан әзерләнгән сораулар, әңгәмә барышында туган сораулар, һөнәри сораулар, гомуми сораулар, кереш, ябык, ачык, өстәмә сораулар, сорау-белдерү, сорау-ярдәм итү, икеләнү, гәҗәпләнү һ.б.. Атаклы журналистларның бу хактагы фикерләре белән танышу.

***Алтынчы тема:*** **Интервью оештыру психологиясе**

Теманы ачар өчен мәгълүмат туплау ысуллары. Геройны дөрес табу. Очрашуны билгеләү, техник чаралар белән эшләү кагыйдәләре.

Психологиянең һөнәри аралашуда һәм иҗатта тоткан урыны. ММЧның социаль-психологик бурычлары. Журналист иҗаты психологиясе. Стресска каршы торучанлык. Интервьюда психологик киртәләр. Аларны җимерү өстендә эшләү. Интервьюга психологик әзерлек, психологик чагылыш юллары.

***Җиденче тема:*** **Интервью жанры - үзенчәлекле сөйләм категориясе**

Интервьюны сөйләм жанры буларак карау. Интервьюда сөйләм адресаты, сөйләм иясе, сөйләм шарты һәм сөйләм нияте төшенчәләре, аларны чагылдыручы тел чаралары. Интервьюда экстра-паралингвистик чараларның роле.

Интервьюда сөйләм адресатының һәм иясенең яшенә карап сөйләм үзенчәлекләре. Интервьюда сөйләм адресатының һәм иясенең  җенесенә карап сөйләм үзенчәлекләре һ.б.

Әңгәмәдәш сөйләменең үзенчәлекләрен саклауның әһәмияте.

***Сигезенче тема:*** **Интервьюның композицион һәм тел-стиль үзенчәлекләре**

Интервью текстын композицион оештыру. Интервьюда башлам (лид), кульминация, очлам өлешләренең үзенчәлеге. Бер блоклы һәм күп блоклы интервью. Интервьюның баш исеме.

***Тугызынчы тема:*** **Интервьюда этика мәсьәләсе**

Журналистның әңгәмә алып бару этикасы. Этиканың барлыкка килүе һәм төп нормалары. Интервьюда этика үзенчәлекләре. Әңгәмәнең тактикасы. Аралашуда конфликт. Аралашуда телдән тыш чаралар. Радио белән телевидениедә әңгәмә этикасы.

***Унынчы тема:*** **ММЧ төрләренә карап интервьюның төрләре**

Басма интервью, радио интервью, ТВ-интервью, интернет интервью. Аларның тель-стиль, композиция үзенчәлекләре. Уртак һәм аермалы яклары. Эшләү тәртибе.

## ТРЕНИНГ-УЕННАР ТЕМАЛАРЫ

**1) “Фото-хәтер” (зрительная память)**

Ике командага бүленәбез (2-3 кеше), калганнары хөкемдарлар. Бер команда читкә китеп тора, икенчесе композиция төзи, тере булмаган әйберләрне дә кулланырга мөмкин. Көндәш команда әлеге композиция белән танышкач, беренче команда тиз арада гына аны үзгәртә. Ике вариант та фотога төшерелә. Көндәш команда композицияне (беренче вариантын) яңадан торгызырга тиеш. Аннары командалар алыша. Төгәл һәм тиз эшләүче команда җиңүче була.

**2) “Кыска конспект” (краткий конспект)**

Һәрбер студентка интервью тексты тәгъдим ителә. Ашыкмыйча танышып чыгабыз. (Ике командага бүленеп эшләргә дә мөмкин). Икенче биттә бернинди сүз, җөмлә кулланмыйча, шул текстны конспектлыйбыз (схема, рәсем, символлар ярдәме белән). Текның эчтәлеген иң якын җиткергән команда – җинүче.

**3)“Эмоциональ хәтерне эшкә җигү” (Эмоциональная память)**

Такта янына иң кыю һәм җитез 2 студент чыга, калганнары игътибар белән тыңлый. Алар эмоциональ рәвештә, ым-ишарәләр, интонация белән интервью текстларын укып чыгалар. Кайсы интервьюның эчтәлеге истә кала, шул кеше җиңә, тыңлаган студентлар, тавыш биреп, җинүчене билгели.

**4)“Соравына күрә җавап”**

Студентларга тема тәкъдим ителә. Берникадәр мәгълүмат алганнан соң, алар әлеге теманы тулысынча ачып бирү максатыннан, сораулар бирә. Сорауларның формасы һәм төрләре кабатланмаска тиеш.

**5)“Лид язабыз”**

Һәрбер студентка интервью тексты тәгъдим ителә. Алар игътибар белән танышып чыккач, әлеге текстка “лид” уйлап табалар. “Лид – (башлам), интервьюның төп идеясын чагылдыручы берничә җөмләдән торган кыска текст. Бер биткә текстның башламын язып, укучылар интервьюлары белән алмашалар. Аннары бергә танышып, иң яхшысы билгеләнә, оригиналдагы варианты да укыла.

**6)“Исем эзлибез”**

“Лид язабыз”дагыча, әмма биредә интервьюга исем уйлыйбыз.

**7) “Интервью уртасы”**

Ике командага бүленеп алып барыла. Бер интервью текстының уртасы белән барысы да танышып чыга. Беренче команда әлеге интервьюның башын уйлап таба, “лид”, исем, әңгәмәгә алып кереп китә торган беренче сорауларны әзерли. Икенче команда интервьюның кульминация өлешен уйлый, нindirәк сораулар бирәчәген һәм ничек тәмамлавын планлаштыра. Соңыннан оригинал текст белән танышабыз.

**8)“Тема мөмкинлеге”**

Интервьюны игътибар белән укып чыгабыз. Тактага шул темага кагылган “ачкыч” сүзләрне язабыз. Шулларга нигезләнеп бөтенләй икенче текст уйлап табарга кирәк.

**9)“Әкияттә кунакта”**

Һәрбер кеше үзе турында кыска әкият уйлап чыгара, моның өчен 20  минут вакыт бирелә. Автор үз әкиятен үзе укып күрсәтә, әмма финал өлешен төшереп калдыра, аны башка кеше сөйли (4-5 җөмлә). Соңыннан автор үз вариантын әйтеп бирә. Ахырда иң әйбәт әкиятчене билгелибез. Бу уен фантазияне үстерергә, кешенең психологик халәтен ачып бирергә ярдәм итә.

**10) “Сорау бирәм”**

Бүген кемне нинди проблема һәм нинди тема борчый? Шул хакта сөйләшү алып барабыз. Һәрбер студент үзенә якын тема сайлый һәм, шуны ачыклар өчен, 10 сорау әзерли, кемгә бирәчәген дә уйлый.

**11) “Сөйләшик әле”**

Һәрбер студент үзен интервью алучы һәм интервью бирүче ролен татып карарга тиеш. Шуның өчен түбәндәге уен тәкъдим ителә. Бу студентларга бер-берсен тагын да яхшырак белер өчен дә файдалы булачак.

Һәрбер мәсьәләгә үзенең фикере булган кыю кеше тактага чакырыла. Калганнар журналистлар ролен үти, сораулар бирә. Һәрберсе азмы-күпме бер-берсен белә, шуның өчен үзенә якын булган темага карата “геройны” ачып бирергә тырышырга кирәк (шәхси тормыш, иҗат, милләт мәсьәләсе, сәясәт, авыл тормышы һ.б.) Сөйләшү тәмамлангач, студент үзенең интервьюсын язып бирә.

**12) “Бездә кунак”**

Танылган кешене кунакка чакыру һәм интервью оештыру. Һәрбер укучының үз темасы һәм юнәлеше. Максат: интервью язу һәм материалны региональ матбугатта бастыру.

**13) “Стилистта кунакта”**

Журналист, әңгәмәгә барыр алдыннан, үзенең тышкы кыяфәтен дә кайгыртырга тиеш. Студентлар “Матурлык салонына” барып, чәч, бит, тырнакны ничек карарга, үзеңне ничек табарга дигән темага, стилист киңәшләрен тыңлыйлар. Аңа профессиональ эшенә бәйле сораулар бирәләр. Интервью языла.

## ЯКЫНЧА СӘГАТЬЛӘР БҮЛЕНЕШЕ

| Индекс | Темалар | Сәг.саны белгечлек буенча | Сәг.саны бакалавриат буенча |
|---|---|---|---|
| **СД.ДС.Ф.5** | Кереш тема | 2 | 1 |
| | Журналистикада жанрлар системасы | 2 | 1 |
| | Нәрсә ул интервью? | 4 | 1 |
| | Алым буларак интервью | 2 | 1 |
| | Интервью жанрның татар матбугатындагы тарихы | 2 | 2 |
| | Һәр журналист сорау бирә | 4 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Интервью оештыру психологиясе | 2 | 1 |
| **Б3.Б.11 бакалавриат буенча** | Интервью жанры - үзенчәлекле сөйләм категориясе | 4 | 2 |
| | Интервьюның композицион һәм тел-стиль үзенчәлекләре | 2 | 2 |
| | Интервьюда этика мәсьәләсе | 2 | 1 |
| | ММЧ карап интервьюның төрләре | 4 | 2 |
| | Тренинг-уен: “Фото-хәтер” | 2 | 0 |
| | Тренинг-уен: “Кыска конспект” | 2 | 0 |
| | Тренинг-уен: “Эмоциональ хәтерне эшкә җигү” | 2 | 0 |
| | Тренинг-уен: “Соравына күрә җавап” | 4 | 2 |
| | Тренинг-уен: “Лид язабыз” | 2 | 1 |
| | Тренинг-уен: “Исем эзлибез” | 2 | 1 |
| | Тренинг-уен: “Интервью уртасы” | 4 | 2 |
| | Тренинг-уен: “Тема мөмкинлеге” | 4 | 2 |
| | Тренинг-уен: “Әкияттә кунакта” | 4 | 0 |
| | Тренинг-уен: “Сорау бирәм” | 4 | 2 |
| | Тренинг-уен: “Сөйләшик әле” | 4 | 2 |
| | Тренинг-уен: “Бездә кунак” | 4 | 2 |
| | Тренинг-уен: “Стилиста кунакта” | 4 | 2 |
| | | | |
| | **Барысы** | **72** | **32** |

## СЕМИНАР ӨЧЕН КОНТРОЛЬ СОРАУЛАР

1. Үзегез укыган берәр интервью буенча әңгәмә барышына йогынты ясаган факторларны ачып бирегез.

2. Берәр тәҗрибәле татар журналистының интервью иҗат итү алымнары белән танышыгыз. Шул хакта кыскача чыгыш әзерләгез.
3. Берәр актуаль темага интервью сорауларын әзерләп килегез.
4. Интервью барышында психологиягә бәйле нинди кызык очракларга эләккәнегез булды? Шул хакта сөйләшү.
5. Әзер интервьюга “лид” язып бирегез.
6. Әзер интервьюга баш исем уйлап табыгыз.
7. Группадашыгыз белән әңгәмә корып, интервью языгыз.

## ИМТИХАН (ЗАЧЕТ) ӨЧЕН СОРАУЛАР

**1 билет.** 1) Интервью жанрында иҗат итүнең төп үзенчәлекләре нинди?
2) Интервьюның эчтәлегенә йогынты ясаучы төп факторларны атагыз.

**2 билет.** 1) Интервью жанрының төрләрен санап чыгыгыз.
2) Интерью жанрының популярлыгы.

**3 билет.** 1) Интервьюны оештыру үзенчәлеге.
2) Интервьюның композицион һәм тел-стиль үзенчәлекләре турында сөйләгез.

**4 билет.** 1) Интервью жанрның татар матбугатындагы тарихы.
2) Алым буларак интервью.

**5 билет.** 1) Жанр буларак интервью.
2) Сорауларның йомшак күчешле һәм кискен күчешле төзелеш төрләре.

**6 билет.** 1) Сорауларның төп функциясе, аларны әзерләү үзенчәлекләре.
2) Журналист иҗатының психологик үзенчәлекләре һәм интервьюдагы роле.

**7 билет.** 1) Интервью жанры - үзенчәлекле сөйләм категориясе.
2) Интервьюда “лид” нәрсәне аңлата һәм ни өчен кирәк.

**8 билет.** 1) Журналистның әңгәмә алып бару этикасы.
2) Аралашуда телдән тыш чаралар.

## ЯЗМА ЭШ ТЕМАЛАРЫ

1. Интервьюның сөйләм жанры буларак структурасы.
2. Сөйләм мотивларына бәйле интервьюның үзенчәлекләре.
3. Интервьюда сорауларның төп функциясе, аларны әзерләү үзенчәлеге.
4. Интервьюның жанрлар системасындагы урыны.
5. Журналистның интервью алу серләре.
6. Интервью жанрының психологик үзенчәлекләре.
7. Алым буларак интервью.
8. Интервьюда башлам (“лид”).
9. Интервьюда сорау алу элементлары.
10. Интервью жанры - үзенчәлекле сөйләм категориясе.
11. Интервьюның композицион һәм тел-стиль үзенчәлекләре.
12. Бүгенге матбугатта интервьюның урыны.
13. Интервью жанрының яңа төрләре.

## БАЛЛ-РЕЙТИНГ СИСТЕМАСЫ РЕГЛАМЕНТЫ

| № | эш төре | баллар |
|---|---|---|
| 1 | Семинар дәресләр | 20 |
| 2 | Уенарда, тренингларда катнашу | 10 |
| 3 | Интервью язу | 20 |
| 4 | Имтихан (зачет) | 50 |

## ТӨП ӘДӘБИЯТ


1. *Гарифуллин В.З.* Журналист эшчәнлегенең нигезләре. Уку ярдәмлеге. Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшр., 2009. 148 б.
2. *Мельник Г.С.* Интервью и его виды // Основы творческой деятельности журналиста. СПб.: Питер, 2006. С. 124 – 129.
3. *Сабирова Л.Р.* Речевые особенности жанра интервью на татарском языке. Казань: Казан. ун-т, 2011. 164 с.


## ӨСТӘМӘ ӘДӘБИЯТ


1. *Белановский С.А*. Глубокое интервью. М.: Николо-Медиа, 2001. 320с.
2. *Белановский С.А.* Методика и техника фокусированного интервью. М.: Наука, 1993. 349 с.
3. Вопрос+ответ = интервью / [Предисл. *В. Пестерла*]. М.: Моск. Рабочий, 1991. 380 с.
4. *Голанова Е.И.* Публичный диалог вчера и сегодня: (коммуникативно-речевая эволюция жанра интервью) // Русский язык сегодня. М., 2000. Вып. 1. С. 251–259.
5. *Голанова Е.И.* Устный публицистический диалог: жанр интервью // Русский язык конца XX столетия. М., 1996. С. 462.
6. *Грабельников А.А*. Работа журналиста в прессе: Учеб. Пособие. М.: РИП-холдинг, 2002. 273 с.
7. *Гарифуллин В.З.* Вакытлы матбугатта жанрлар төрләре һәм төзелеш үзенчәлекләре. Казан, 2006. 90 б.
8. *Ильченко С.Н*. Интервью в журналистском творчестве. СПб.: СПбГУ, 2003. 93 с.

9. *Кантор Ю.З.* Диалогический текст интервью в коммуникативном аспекте: (на материале соврем. рос. газет): дис. ... канд. филол. наук; Санкт-Петерб. гос. ун-т. СПб., 2001. 191 с.

10. *Карнеги Д.* Как зовоевать друзей и оказывать влияние на людей. Л.: Прогресс, 1992. 412 с.

11. *Красноперова Ю.В.* Дискурсивные стратегии участников интервью: дис. ... канд. филол. наук. Иркут. лингв. ун-т. Иркутск, 2005. 239 с.

12. *Лукина М.* Технология интервью: учеб. пособие для вузов. М.: Аспект Пресс, 2003. 191 с.

13. *Мельник Г.С.* Психология профессионального общения в журналистике: Учебное пособие / Санкт-Петерб. гос. ун-т., 2001. 159 с.

14. *Мельник Г.С*. Общение в журналистике: секреты мастерства. СПб.: Питер, 2005. 217 с.

15. *Моисеев В.А.* Журналистика и журналисты: (о самой интересной профессии). Киев: Дакор, 2002. 402 с.

16. *Низамов И.М.* Татарская речь: функционирование и развитие речевой системы в массовой коммуникации. Казань: Матбугат йорты, 2002. 272 с.

17. *Низамов И.М.* Татар соцолингвистикасы. Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшр., 2006. 152 б.

18. *Олешко В.Ф*. Журналистика как творчество, или что нужно делать, чтобы читатели, телезрители, радиослушатели тебя понимали и вступали в диалог: Учеб. пособие / Екатеринбург: Изд-во Урал. ун-та, 2002. 188 с.

19. *Пиз А*. Язык разговора / А. Пиз, А. Гарнер. М.: ЭКСМО-Пресс, 2001. 224 с.

20. *Сазанов Г.* Пришел – поговорил – написал... // Журналист. 2004. №1. 79-80 с.

21. *Тертычный А.А.* Жанры периодической печати: учебное пособие. М.: Аспект Пресс, 2000. 311 с.

**Электрон ресурслар:**

22. Журналист [Электронный ресурс] Journalist PRO: интернет-издание. URL: http://www.journalist-pro.com/2007/10/21/lid

23. *Леонтьева Г.* Мой любимый жанр интервью [Электронный ресурс] // Петерб. союз журналистов. 2005. № 2. URL: http://www.journalists.spb.ru/publish/newspaper